**Анна Ивановна Солтанова-Бустерякова –**

**Хезмәт ветераны, КамАЗ төзелеше ударнигы,**

**РСФСРның мәгариф отличнигы.**



## Онытылмас еллар хатирәсе

Мин Солтанова Анна Ивановна (Бустерякова) икенче сыйныфтан башлап Яр Чаллы шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә укыдым.Алабуга укытучылар институтын “отлично”га тәмамлап, гомерем буе туган мәктәбемдә татар теле һәм әдәбиять укыттым, уку-укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, шәһәр һәм Чаллы районы татар мәктәпләре инспекторы да булдым. Казан Дәүләт педагогия институтын тәмамладым.Чирек гасыр шәһәр һәм район татар теле укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе , әдәбият түгәрәге, факультатив җитәкчесе булып эшләдем. Татар теле кабинеты булдырдым. Атналык йомгаклар буенча сыйныфларны гомуми линейкага әзерләдем. Трибун шагыйрь Һади Такташ әсәрләренең сүзлек составын өйрәнү буенча 10 мең карточка тутырдык. Төрле курсларда укып, татар дөньясының иң күренекле галимнәреннән өстәмә белем алдым. Лаеклы ялда да мәктәп тормышыннан аерылмадым, шуннан көч алып, рухланып яшим.

Үз телемдә сүз әйтимче,

И дөнья колагыңа!

Гомер кыска, җавап көтмим,

Син бары тыңла гына.

Ишет кенә, сикерт кенә

Чал кашыңны, сокланып,

“О бөек Тукай теле!” – дип,

Тәүге аваздан танып. (Сирень Якупова)

1924нче елның 13нче февралендә Борды авылында тудым. (Чаллы, Тукай районы). Гаиләдә җиде кыз, бер малай. Мин өченче бала. Бу Россия өчен бик авыр еллар була бу. Беренчедән, юлбашчыбыз В. И. Ленин вафат. Икенчедән, рус җирендәге озакка сузылган ачлыктан гади халык тәмам хәерчеләнә. Ашау булмагач, әнинең күкрәк сөте юк. Бишек баласына да ашатырга да һич ни юк. Бәрәңге боламыгы бирәм, ул да сөтсез. Бу бала белән ни булыр инде? – дип, үзем куркам. Ирем эшкә барасы, аңа бар кебек бәрәңгене пешерәм, ә үзем, яңа гына бала тудырган хәлсез ана, ул киткәч, бәрәңгенең кабыгын ашыйм – ачка үләсем килми. Йөрергә дә хәл юк, тез буыннары калтырый, йөрәгем сызлый. Әздән генә исән калдык, -дип, ничә еллардан соң да мөлдерәмә ачы күз яшьләре белән искә ала иде бичара әни.

Беренче сыйныфны авыл мәктәбендә укыдым. Бер генә ел укысам да, гомерем буе онытылмаслык булып хәтердә калган. Беренче укытучым Варвара Петровна хәзер дә истә, хәзер дә күз алдымда. Бик сабыр, без балаларны бик ярата иде.Тагын бер укытучыны гомерем буе хөрмәт иттем. Ул Ленин орденлы Вера Лавровна – бөтен республикага данлыклы рус теле укытучысы. Балачакта ул әнинең иптәш кызы кызы булган, бергә уйнап үскәннәр.Әни дә укырга бик сәләтле иде, мөмкинлекләре булмады, - дип искә ала иде. Икенче сыйныфка Вахитов мәктәбенә бирделәр. Шуннан бирле мин Яр Чаллыда яшим. Бер гаиләдән биш бала укыдык Вахитовта. Кичен өйдә дәрес хәзерләгәндә өстәл янында урын да җитми иде, җиделе лампа яктысы да калтырап кына тора иде. Хәзер искә төшереп уйлыйм, күз алдына китерәм: без туганнар үзара дус идек, яратып, тырышып укыдык, барыбыз да белемле, тәрбияле кешеләр булып үстек. Гомеребез буе тырышып, яратып эшләдек. Һәр эшне яхшы, төгәл итеп эшләргә өйрәндек. Нинди генә эштә булсак та, җиренә җиткереп яхшы нәтиҗә белән эшләдек. Шуңа күрә безгә теләсә

нинди катлаулы. Җаваплы эшләрне ышанып тапшыралар иде. Тырыш, төгәл, җитез, гадел, намуслы, тәртипле булырга әти-әни, әби-бабайдан күреп үскәнбез. Әти утыз алты яшьтә кинәт үлеп китте. Без бер анага алты ятимә кыз, әби-бабай калдык. Брдәнбер энебез сигез яшьтә җизгәк авыруыннан вафат булды. Ул вакытта шәһәр бик кечкенә, эшләргә эш табуы кыен. Ай ярым стажың тулмый дип балаларга пенсия дә бирмәделәр. Ә авылда эшләгән стажга саналмый икән. Күз алдына китерегез, бу ятим гаиләгә ничек яшәргә?..Әни безне эшкә өйрәтте. Ачтан үлмәс өчен эшләргә кирәк иде. Кечкенәдән үк яхшы эшләргә, җаваплылык белән мөстәкыйль эшләргә өйрәндек. Туганнар һәркайсыбыз укып һөнәр алдык, гомеребез буе эшләдек. Эшеңне яратып, чын күңелдән эшләсәң, нәтиҗәсе дә күренә. Мактанырга җыенмыйм. Гадәтем шундый, берәр эшемне мактый башласалар, бик оялам, уңайсызланам. Әни бик тыйнак кеше иде. Мактанчыкларны бер дә яратмады. Озын гомер буена эшләгәннәрне язып бетерә торган түгел...

Шагыйрә Ә. Ситдикова бик матур әйткән:

Үткәннәргә күз салсагыз әгәр,

Үкенерлек мизгел булмаган.

Төсле бизәк булып изге эшләр

Карап тора узган еллардан.

Мәктәпкә мин һәрвакытта да уйлап билгеләгән план белән дәресләрдән соң өстәмә төрле тәрбия чаралары да башкарырга әзерләнеп бара идем.Шуңа күрә, эшем дә күп була. Яшермим, балаларны яратып эшләдем, шатланып эшләдем. Укытучы булуны югары бәяли идем. Без, укытучылар, укытучы булуыбыз белән горурланып яшәдек.

“Безнең  яшьләребезнең беренче тәрбиячесе кем? Укытучы. Укытучы! Сүзе генә дә нинди! Укытучы! Әйтүе генә җиңел! Һәр бала укый торган безнең илебездә укытучы – беренче кеше ул. Безнең балаларыбызның, халкыбызның киләчәге – укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә”,  - дигән бит безнең бөек рус язучысы А. Фадеев.



2нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең укытучылары, 1979 ел.

Без мәктәбебезне чын мәгънәсендә яраттык, үз иттек. Укучы балаларны, аларның ата-аналарын эчкерсез хөрмәтләдек. Барыбыз бер тату-дус, зур гаилә кебек иде. Барыбыз да максатлар белән эшләдек: яшь буынга тирән белем бирү, һөнәрле итү, туган илебезгә – Ватаныбызга лаеклы кешеләр тәрбияләп чыгарырга тырыштык. Мәктәпнең укытучылар коллективы уңышларга ирешә килде.Совет кешеләре – халкы Бөек Ватан сугышында моңа кадәр әле җир йөзендә күрелмәгән зур сынау үтте: Совет Армиясе, бернинди авырлыкларга да карамастан, сан ягыннан да, кораллары белән дә үзеннән берничә мәртәбә көчлерәк булган немец фашистларын бөтен дөнья – илләр, халыклар алдында хурлыкка калдырып җиңде һәм үз оясында тар-мар итте. Быел Бөек Җиңүнең 71 еллыгы. Әйтеп бетергесез зур куаныч, иксез – чиксез шатлык көне! Бөтен халык, кешелек дөньясы өчен олы, иң кадерле Җиңү бәйрәме.Туган илебезнең, халкыбызның киләчәген, хәзерге мул, матур, иректе тормышыбызның язмышын хәл иткән Бөек Җиңү Көне, барыбыз өчен дә иң Изге көн! Аллаһыбыз тарафыннан яратылып бирелә торган бердәнбер тормышын да аямыйча, безне саклап калыр өчен батырларча көрәшеп һәлак булганнарны искә алу көне дә. Әйтергә генә ансат, ничәмә миллион бер

гөнаһсыз кешеләр әрәм булды, күбесе гомерлек гарип булып газап чикте. Ятим балалар белән илләр тулды, авыл-шәһәрләр, завод-фабрикалар җимерелде. Бары халкыбызның үзара дус, бердәм, тырыш булып, бар көчен биреп эшләве, илен яратуы, аны дошманнан саклап калырга бөтен көчен куюы, патриот совет кешесенең һәрвакыт дошманны җиңүгә ышанып эш итүе, шуңа омтылуы фронт белән тылның бердәмлеге ярдәмендә Ватаныбыз Советлар Союзы безнең барыбызны да, шулай ук бөтен европа илләре халыкларын да немец-фашист коллыгыннан азат итте. Беренче көннәреннән үк безнең мәктәпнең ир-ат укытучылары да сугыш кырларында батырларча көрәште. Яшьләре җитәр-җитмәс үк мәктәп эскәмьясеннән сугышка китүчеләр дә булды. 1942 нче елда мәктәп директоры Сөләйман абыйны да (Кузюров Сөләйман Мотыгуллович) озаттык. Шунда ук ятим калгандай булдык. Әмма мәктәп тагы да тырышыбрак эшләде. Ул елларда кышлар котычкыч салкын булды. Мин 9нчы сыйныфта укый идем. Көненә бер генә мәртәбә уты ягып җылытыла торган сыйныф бүлмәләре икенче сменага бик суына, хәтта савыттагы язу карасыда бозлана иде. Стенадагы унлы я җиделе пыяла куыклы керосин лампасының эңгер-меңгер яктысында 5-6 дәрес утырып, белем алырга тырышабыз, күңелдән генә тәнәфесне көтәбез. Чыгып йөгергәләп аякларны җылытырга хыялланабыз. Дәрестә укучылар да, укытучылар да өс киеменнән булса да, Искәндәров фамилияле өлкән укытучыбыз һәрвакыт бик туңа иде. Өстенә юка кием, үзе бик ябык та, сөйләве дә авыр. Без, укучылар, аны бик кызгана идек. Шул күренешләр күз алдыма килсә, 70 елдан соң да йөрәгем тетрәнеп чәнчешә башлый. Менә нәрсә бит ул сугыш! Бөтен яклап, хәтта тылда да тормышны җимерә. Бөтен нәрсә фронт өчен, дошманны җиңәр өчен булды. Бер кеше дә ыңгырашмады. Ничек кенә кыен булса да, һичкем зарланмады. Балалар барысы да яхшырак укырга тырышалар иде. Җәмгыять эшләренә дә бик теләп катнаштык. Мәктәпкә утын кисеп әзерли идек. Ишек алды. Мәктәп тирәсе урамнарда агачлар утыртып үстердек. Мәктәп бакчасында эшләдек. Колхоз басуларына ярдәмгә бардык. Кыр эшләре кар яуганчы дәвам итә иде. Машина – тракторлар аз, атларның да көчлеләре фронтка китте. Бөтен эш хатын-кыз. Мәктәп балалары, картлар өстенә төште. Һәр эштә теләп катнаштык. Ничек тә дошманны җиңүне якынайтырга тырыштык. Һәркем бу каһәрле, дәһшәтле бер гаепсез кешеләрне, хәтта балаларны, картларны, авыруларның да канын коючы вәхши сугышның тизрәк бетүен теләде. Минем өчен, гаиләм өчен сугыш еллары берничш мәртәбә авыррак булды. Без инде утыз алтынчы лдан бирле ятимлелек шулпасын эчтек. Җылап-ыңгырашып йөрмәдек, яшәргә тырыштык. Директорыбыз Сөләйман абый, озын-озак сугышның җәһәннәмле юлларын үтеп, Берлинга барып җитте. Рейхстангны алгач, диварына исемен

язып, күкрәк тулы орден-медальләр белән туган мәктәбенә исән-имин әйләнеп кайтты. Мәктәпне бик сагынып кайткан. Беренче көнне үк эшкә кереште. Без аны директорларның директоры дип йөртә идек. Ул аңа, һичшиксез, лаеклы иде. Татарстанның атказанган укытучысы Сөләйман Мотыйгуллович Кузюров без яшьләрне дә чын укытучылар итеп тәрбияләргә бөтен көчен куйды.Бу вакытта мин, (бер анага алты ятимә кызның өченчесе), Алабуга укытучылар институтын отличнога тәмамлап, мәктәбемдә укыта идем. Без ул башлаган уңай традицияләрне лаеклы дәвам иттек. Ягъни, лаеклы дәвамчысы булдык.



Анна Ивановна Солтанова – Бустерякова

Безне бернинди авырлыклар да куркытмады, төшенкелеккә бирелмәдек. Чын мәгънәсендә ихлас күңелдән, тырыша-тырыша, йөгерә-йөгерә эшләдек. Укытучы булу безнең өчен чиксез горурлык иде, безгә рухи көч биреп торды. Ихластан бирелеп эшләгәндә, коллектив өчен ирешеп булмый торган үрләр юк икән. Шуны күреп, ата-аналар газиз балаларын ышанып безгә – татар мәктәбенә китерде. Уку-укыту эшләренең нәтиҗәле була баруы, шәһәр күләмендә күп төрле җәмгыятькә файдалы эшләрдә катнашу һәм алдынгылык яулау да мәктәпнең дәрәҗәсен күтәрде.

Кайсы гына фәнне алсаң да, көчле укытучылар иде бездә: Ленин орденлы Шәмсия Шакировна Абдукаева, Татарстан атказанган укытучысы Имам Хәйдәрович Хәйдәров. Безнең өчен һәр дәрес кадерле иде. Үзем әдәбият түгәрәге оештырдым. Төрле әдәби – музыкаль кичәләр, җыр-шигырь бәйрәмнәрендә укучылар бик теләп катнаштылар. Утыз алты ел буена татар теле һәм әдәбияте укыттым. Әдәбият түгәрәге әгъзалары әдипләр белән хатлар язышты. Казанда Язучылар берлегендә булдык, алар безнең мәктәпкә бик теләп киләләр иде. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен исә мәктәпнең гомерлек дустына әверелде. Мәшһүр композиторыбыз Җәүдәт Фәйзине укучылар белән Казанга барып үзебезгә чакырып китердек. Александр Ключарёв, Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Венера Ганеева, Флёра Сөләйманова, Җәваһирә Рәләхова. Рафаэль Ильясов, үзебезнең укучыбыз Галина Казанцева кебек сәнгать осталарын күрү бәхетенә ирештек.



2нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә Мулланур Вахитов кичәсеннән соң.

Уртада беренче рәттә Мулланур Вахитовның икенче буын туганы – рәссам Исхаков.

1964 нче елда “Социалистик Татарстан” газетасында Габдрахман Әпсәләмов “Әдәбияткә гомер иярә” мәкаләсендә безнең мәктәп турында болай дип язды: “Биредә әдәбиятны чынлап торып яраталар, өйрәтәләр, өйрәнәләр, укыйлар һәм олылыйлар”. Мәктәп дирекциясе әдәбият түгәрәге әгъзаларына Казанга бару мөмкинлеге бирде. Без Ленин орденлы язучыбыз Шәриф Камал музеенда булдык, хатыны Хәят апа һәм кызы Зәйнәп белән дә таныштык. Мин җитәкләгән әдәбият түгәрәге мәктәп күләмендә “Яшь буын ” исемле гәҗит чыгарды. Сайланма иҗат җимешләрен утыз алты альбомда тупладык.



Муса Җәлилгә 60 яшь тулу уңаеннан бәйрәм тантаналарында. Уңнан сулга – Чулпан һәм Әминә Җәлил, Андре Тиммерманс хатыны белән, 2нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары Анна Солтанова-Бустерякова, Хаҗәр Гәрәева. Казан. 1966 нчы ел.

Мәктәп китапханәсе белән берлектә китап укучылар конференцияләре дә бик эчтәлекле, җанлы үтә иде. Язгы каникулда уза торган шәһәр сәнгать олимпиадасына без яңалык керттек. “Туган җирем Татарстан” темасына бай эчтәлекле чыгышыбызны жюри югары бәяләде. Алга таба олимпиадалар тематик үтә башлады.




2нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең 1964 нче елгы чыгарылышы, директоры Фәрдиев Наил Габдрахман улы




2нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең 1974 нче елгы чыгарылышы, директоры Яковлева Г. И.

Бердәм булып, дус, ярдәмләшеп эшләгәндә генә югары уңышларга ирешеп була. Гимназиянең уңышларына шатланып, куанып яшим. Лаеклы ялда мин бервакытта да эшсезлектән ямансулап утырмадым. Минем һәрвакыт шөгылем булды. Укырга бик яратам. Балаларым, туганнарымнан кала хезмәттәшләрем белән телефоннан аралашам. Кул эшләрен, бакча эшләрен яраттым, гөлләр үстерәм. Хәзер дә оныкчыкларга дәрес әзерләргә булышам. Укучыларым язмышы күңелемдә. Күрешеп, хәбәрләшеп яшибез.



2нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә Алабуга педагогика институтының доценты Мәһинур Фәйзуллина (уртада) белән практикада.

Газиз мәктәбем, кадерле укучыларым, хөрмәтле хезмәттәшләрем һаман да истә. Сагынып искә алырдай яхшы юлдашларың булуны иң кадерле байлыгым, иң зур бәхетем дип беләм.




2нче гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучыларының 1966 нчы елгы чыгарылыш укучылары белән очрашуы, 2001 ел.